**Казан шәһәре Башкарма комитетының**

**2024 елның 9 августындагы 3341 номерлы карары**

**Казан шәһәренең Киров районында**
**ачык сервитут билгеләү турында**

1. Әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитут характеристикасы:

- йогынты ясала торган мәйдан – 253 кв.м;
- тиешле җир кишәрлегенең кадастр номеры – 16:50:280101:1369;
- урнашкан урыны: Казан шәһәре, Киров районы;
- билгеләү максаты: транспортта һәм җәяү узуны тәэмин итү;
- билгеләү вакыты: 49 ел;

1.2. гариза бирүче: «Казан медицина аппаратурасы заводы» акционерлык җәмгыяте;

1.3. билгеләү нигезләре: гариза бирүче мөрәҗәгате, Россия Федерациясе Җир кодексының 23 статьясындагы 4 пункты, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон.

2. «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарның 1, 2 номерлы кушымталары нигезендәге чикләрдә ачык сервитутның йогынты ясау өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итәргә.

3. Әлеге карарның 2 номерлы кушымтасыннан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга һәм Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

5. «Казан медицина аппаратурасы заводы» акционерлык җәмгыятенә тәкъдим итәргә:

5.1. Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының 2021 елның 24 июнендәге 2293 номерлы «Казан (Борисоглебское) эксперименталь авиация аэродромының аэродром яны территориясен билгеләү турында»гы боерыгы нигезендә «Казан (Борисоглебское) эксперименталь авиация аэродромының 3 нче һәм 4 нче аэродром территориясе ярдәмче зоналары өчен билгеләнгән чикләүләрне үтәргә;

5.2. Идел суалгычының, сууткәргеч корылмаларының санитар саклау зонасының 2 һәм 3 поясларында, «Казан дәүләт казна дары заводы» федераль казна предприятиесе сууткәргеченең санитар саклау полосасында урнашуына бәйле рәвештә җир кишәрлегеннән файдалану буенча чикләүләрне үтәргә, 16:50-6.9472, 16:50-6.9474 зоналары;

5.3. җир кишәрлегенең «Казан медицина аппаратурасы заводы» акционерлык җәмгыяте мәйданчыгы өчен санитар-саклау зонасында урнашуына бәйле рәвештә чикләүләрне үтәргә, 16:50-6.7800 зонасы;

5.4. җир кишәрлеге «Телефон канализациясе» сак зонасында булуга бәйле рәвештә чикләүләрне үтәргә, 16:50-6.7230, 16:50-6.7834 зонасы;

5.5. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 24 февралендәге 160 номерлы карары белән расланган электр челтәре хуҗалыгы объектларының саклау зоналарын билгеләү кагыйдәләре һәм мондый зоналар чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның махсус шартлары белән билгеләнгән чикләүләрне үтәргә, 16:50-6.16, 16:50-6.6093 зонасы;

5.6. Казан шәһәре, Киров районы, Набережная урамы, 31А йорт, (16:50-6.6923 зона) адресы буенча урнашкан «ТАШКОЯР» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте предприятиесе өчен санитар-саклау зонасы чикләрендә җир кишәрлегенең урнашуына бәйле чикләүләрне үтәргә;

5.7. су саклау зоналары һәм яр буе яклау полосалары өчен Россия Федерациясе Су кодексының 65 статьясындагы 15, 16, 17 өлешләрендә билгеләнгән чикләүләрне үтәргә, 16:50-6.9630 зонасы;


5.8. санитар саклау зоналарының өченче поясы кагыйдәләре белән билгеләнгән чикләүләрне үтәргә, 16:50-6.9626 зонасы.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәфигуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

1 номерлы кушымта
Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 9 августындагы
3341 номерлы карары белән
расланды

**16:50:280101:1369 кадастр номерлы җир кишәрлегенә ачык сервитут йогынтысы өлкәсе чикләре**




Масштаб 1:500
Координаталар системасы: МСК-16

| Шартлы билгеләр: | |
|---|---|
| 1 | яңа ясалган характерлы нокта |
| | билгеләнә торган сервитут чиге |
| | булган җир кишәрлекләренең чиге |
| | территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар (гамәлдәге) |

| | |
|---|---|
|  | кызыл линияләр (гамәлдәге) |
|  | капиталь төзелеш объектлары |
| 16:50:280101 | кадастр кварталы |
| 16:50:280101:1369 | хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры |

---